# КИЛЕН ТӨШКӘНДӘ

*РӨСТӘМ ЯХИН музыкасы*
*РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН сүзләре*

Ак күбеккә баткан юргалар
Кышкы юлдан ярсып чабалар.
Чак-чак кына аумый калалар
Салулаган чакта чаналар,
Арттан чаба бала-чагалар,

Мамык мендәрләргә төренеп,
Килен төшә бүген авылга.
Борынгыдан калган гадәт ул —
Халык чыга каршы алырга,
Яшь кәләшне күреп калырга.

Җилкендереп япь-яшь кызларны,
Килен төшә бүген бер өйгә.
Кайда калды шундый чагым, дип,
Авыр сулап куя әниләр,
Авыр сулап куя әбиләр.

Күптән инде ачып куйганнар
Килен төшкән өйнең капкасын.
Килен төшкән өйнең капкасын.
Китәргә дип кире япмасын,
Кайгы җиле килеп какмасын.